КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2023 ел, 6 октябрь | г.Казань | № 1253

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү стратегиясен раслау турында» 2010 ел, 10 февраль, 61 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 9 февраль, 93 нче карарының 16 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Урта һөнәр белеме бирүче «Лубян урман-техник көллияте» дәүләт бюджет белем учреждениесенең исемен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 ел, 26 сентябрь, 711 нче карарының 5 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары белән керүен чикләүне кертү турында» 2021 ел, 25 август, 780 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары белән керүен чикләүне кертү турында» 2023 ел, 4 май, 569 нчы карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин